РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» ноябрь 2020ел г. Альметьевск № 1644

2021 елга Әлмәт муниципаль районы
гомуми белем бирү учреждениеләренең
норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2007 елның 11 декабрендәге 3100 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләре каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны расларга (1 нче кушымта).

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2019 елның 12 декабрендәге 2143 номерлы карары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

3. «2021 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2020 елның 26 сентябрендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган гомуми белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнары нигезендә гомуми белем бирү учреждениеләрен финанслауны тәэмин итүне Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Шәйдуллина З.Р.) тәкъдим итәргә.

4. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Зак. № 3063

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Л.Ф.Вәлиев

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
«11» ноябрь 2020 № 1644
белән расланган
1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләре каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, сум в год |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 92 851 |
| | авыл җирлеге | 94 213 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 139 227 |
| | авыл җирлеге | 143 701 |

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева